КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 сентябрь г.Казань № 735

2024/2025 уку елында Татарстан Республикасында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1999 елның 31 декабрендәге 1441 нче карарын үтәү йөзеннән һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүне камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024/2025 уку елында Татарстан Республикасында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча төп чаралар планын расларга.

2. Ведомство буйсынындагы белем бирү оешмалары булган Татарстан Республикасы министрлыкларына түбәндәгеләр буенча чаралар күрергә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан предприятиеләргә, оешмаларга һәм учреждениеләргә, Россия Федерациясе территориясендә эшчәнлек алып барырга рөхсәт ителгән иҗтимагый берләшмәләргә әлеге чаралар күрүне тәкъдим итәргә:

хәрби хезмәткә чакыруга кадәрге яшьтәге гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү;

белем бирү оешмаларында, уку-укыту пунктларында, шулай ук хәрби-патриотик, яшьләр һәм балалар берләшмәләрендә гражданнарга хәрби-патриотик тәрбия бирү эшен оештыру;

белем бирү оешмаларының, уку-укыту пунктларының, спорт комплексларының һәм гражданнарга патриотик тәрбия бирү һәм аларны хәрби хезмәткә чакыруга кадәр әзерләү үзәкләренең уку-укыту-матди базасын камилләштерү;

гамәлдәге спорт-гамәли һәм хәрби-техник секцияләр һәм клублар эшләү;

хәрби хезмәткә чакыруга кадәрге яшьтәге гражданнарга хәрби-патриотик

тәрбия бирү эшен оештырганда белем бирү оешмаларының, предприятиеләрнең, оешмаларның, учреждениеләрнең һәм муниципаль берәмлекләрнең спорт инфраструктурасын актив файдалану.

3. Ведомство буйсынындагы белем бирү оешмалары булган Татарстан Республикасы министрлыкларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча) һәм Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) белән берлектә, түбәндәгеләр буенча эшне дәвам итәргә:

белем бирү оешмаларын һәм уку-укыту пунктларын педагогик кадрлар белән комплектлау;

Татарстан Республикасында кадетлар белем бирүне үстерү.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына хәрби исәпкә беренчел куелганнан соң профилактик медицина тикшерүләре нәтиҗәләре буенча һәм хәрби хезмәткә чакыру нәтиҗәләре буенча хәрби хезмәткә чакыруга кадәрге яшьтәге һәм хәрби хезмәткә чакыру яшендәге мохтаҗ гражданнарга үз вакытында һәм тулы күләмдә дәвалау-савыктыру чараларын уздыруны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары белән берлектә, гражданнарга патриотик тәрбия бирү, хәрби хезмәт узуга кызыксынуны арттыруга, хәрби хезмәткә чакырылучыларны даими нигездә социаль яклау буенча массакүләм мәдәни чаралар үткәрергә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023/2024 уку елында Татарстан Республикасында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү турында» 2023 ел, 21 август, 998 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 6 сентябрь, 735 нче
карары белән расланды

2024/2025 уку елында Татарстан Республикасында
гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча төп чаралар
планы

| Т/с | Чараның исеме | Җаваплы башкаручы | Үткәрү срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| I. Оештыру чаралары | | | |
| 1. | Төп планлаштыру документларын эшләү, шул исәптән 2023/2024 уку елында хәрби хезмәт нигезләре буенча уку җыемнарын оештыру һәм уздыру турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе проекты | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | уку елы дәвамында |
| 2. | Татарстан Республикасының хәрби частьлары һәм муниципаль берәмлекләре арасында шефлык элемтәләрен киңәйтү буенча эшләр башкару | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган республика башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм күрсәтү буенча ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча), Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) | уку елы дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | буенча идарәсе (килешү буенча) | |
| II. Хәрби хезмәткә әзерлекне кадрлар белән һәм укыту-методик яктан тәэмин итү | | | |
| 1. | Белем бирү оешмаларын «Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре» укыту предметын оештыручы укытучылар белән туплау | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган республика башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) | даими |
| 2. | «Тормыш эшчәнлеге иминлеге нигезләре» һәм «Тормыш эшчәнлеге иминлеге» курсларын укыту өчен укыту-методик һәм күрсәтмә әсбаплар белән тәэмин итүдә мәгариф оешмаларына ярдәм күрсәтү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган республика башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча), «Хәрби-спорт әзерлеген үстерү һәм патриотик тәрбия бирү үзәге» өстәмә һөнәри белем бирү коммерциягә карамаган автоном оешмасының Татарстан Республикасындагы филиалы (алга таба – ХСӘПТҮҮнең Татарстан Республикасындагы филиалы) (килешү буенча) | даими |
| 3. | Хәрби хезмәткә әзерлек мәсьәләләре буенча конференцияләр һәм семинарлар үткәрү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган республика башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм күрсәтү буенча ирекле | уку елы дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | җәмгыяте (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча), ХСӘПТҮҮнең Татарстан Республикасындагы филиалы (килешү буенча) | |
| 4. | «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм күрсәтү буенча ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе тарафыннан белем бирү оешмаларының җитәкче составы белән укыту-методик җыеннар үткәрү | «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм күрсәтү буенча ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) | уку елы дәвамында |
| | III. Гражданнарны хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерләү | | |
| 1. | Гражданнарны хәрби хезмәт нигезләре буенча укытуны оештыру | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган республика башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), «Патриот» яшьләрне спорт-патриотик һәм хәрби хезмәткә кадәр әзерләү буенча республика үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе (алга таба – «Патриот» РҮ ДАУ) (килешү буенча) | уку елы дәвамында |
| 2. | Гомуми белем бирү оешмаларының һәм һөнәри белем бирү оешмаларының 10 сыйныф укучылары белән хәрби хезмәт нигезләре буенча уку җыеннарын үткәрү һәм «Авангард» | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган республика башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү | 2024 елның сентябре – 2025 елның июне |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | уку-укыту һәм методик җыеннар үткәрү | буенча), Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Жуков орденының Казан югары танк командасы Кызыл Байрак училищесы» югары белем бирү федераль дәүләт казна хәрби учреждениесе (килешү буенча), «Патриот» РҮ ДАУ (килешү буенча), «Патриот» хәрби-патриотик эш һәм яшьләрне хәрби хезмәткә кадәр әзерләү үзәге (Түбән Кама шәһәре) (килешү буенча), «Ватан» хәрби-патриотик эш һәм яшьләрне хәрби хезмәткә кадәр әзерләү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе (Чистай шәһәре) (килешү буенча) | |
| 3. | Гомуми белем бирү оешмаларының һәм һөнәри белем бирү оешмаларының 10 сыйныф укучылары белән хәрби хезмәт нигезләре буенча уку җыеннары үткәрү | ведомство буйсынуындагы мәгариф оешмалары булган Татарстан Республикасы министрлыклары, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Жуков Кызыл Байрак училищесы Жуков орденының югары танк хәрби белем бирү федераль дәүләт казна хәрби | уку елы дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
| --- | --- | --- | --- |
| | | учреждениесе (килешү буенча) | |
| 4. | Хәрби хезмәт нигезләре буенча слетлар, ярышлар, конкурслар, олимпиадалар үткәрү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган республика башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм күрсәтү буенча ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы югары уку йортларының ректорлар советы (килешү буенча), Татарстан Республикасында ХСӘПТҮҮ филиалы | уку елы дәвамында |
| IV. Гражданнарга хәрби-патриотик тәрбия бирү | | | |
| 1. | Белем бирү оешмаларында Ватан тарихына багышланган батырлык дәресләре, сыйныфтан тыш чаралар үткәрү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган республика башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм күрсәтү буенча ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча), Россия Федерациясе | уку елы дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча), ХСӘПТҮҮнең Татарстан Республикасындагы филиалы (килешү буенча) | |
| 2. | Белем бирү оешмаларында Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган музейлар һәм хәрби дан почмаклары буенча смотр-конкурс үткәрү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган республика башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм күрсәтү буенча ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча), Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча), ХСӘПТҮҮнең Татарстан Республикасындагы филиалы (килешү буенча) | уку елы дәвамында |
| 3. | Ватанны саклаучылар көненә һәм Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган оборона-массакүләм һәм спорт эше буенча чаралар үткәрү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган республика башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты | уку елы дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм күрсәтү буенча ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча), Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча), ХСӘПТҮҮнең Татарстан Республикасындагы филиалы (килешү буенча), «Патриот» РҮ ДАУ (килешү буенча) | |
| 4. | «Хәрби хезмәткә чакырылучылар көне» республика социаль-патриотик акциясен үткәрү | Муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Жуков орденының Казан югары танк команда командасы Кызыл Байрак училищесы» югары белем бирүче федераль дәүләт казна хәрби мәгариф учреждениесе (килешү буенча), «Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Казан Суворов хәрби | 2024 елның 15 ноябренә кадәр, 2025 елның 15 маена кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | училищесы» федераль дәүләт казна гомуми белем бирү учреждениесе (килешү буенча), Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) | |
| 5. | Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган чакырылырга тиешле гражданнар арасында хәрби-гамәли һәм спорт-техник спорт төрләре буенча ярышлар үткәрү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган республика башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм күрсәтү буенча ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча), Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Жуков орденының Казан югары танк команда командасы Кызыл Байрак училищесы» югары белем бирү федераль дәүләт казна хәрби мәгариф учреждениесе (килешү буенча), «Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Казан Суворов хәрби училищесы» федераль дәүләт казна гомуми белем бирү учреждениесе (килешү буенча), Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча), Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре | уку елы дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча), ХСӘПТҮҮнең Татарстан Республикасындагы филиалы (килешү буенча), «Патриот» РҮ ДАУ (килешү буенча) | |
| 6. | Балалар һәм яшьләрнең Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре хәрби комиссариатлары вәкилләре, шулай ук Бөек Ватан сугышы, Әфганстан сугышы, Төньяк Кавказда терророрчылыкка каршы операцияләр ветераннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар белән очрашулары һәм хәрби дан көннәре үткәрү | Ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмалары булган республика башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм күрсәтү буенча ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча), Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча), ХСӘПТҮҮнең Татарстан Республикасындагы филиалы (килешү буенча), «Патриот» РҮ ДАУ (килешү буенча) | уку елы дәвамында |
| 7. | Хәрби-патриотик яшүсмерләр клубларының һәм «Юнармия» бөтенроссия балалар һәм яшүсмерләр хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәтенең республика слетын үткәрү | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) | уку елы дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 8. | Югары белем бирү мәгариф оешмалары укучылары арасында хәрби җыр фестивале үткәрү | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы каршындагы тәрбия эшләре буенча координация советы (килешү буенча) | уку елы дәвамында |
| V. Медицина таныклавы һәм медицина тикшерүе | | | |
| 1. | Гражданнарны медицина тикшерүендә катнашучы республика шәһәрләре һәм районнары табиб-белгечләре белән инструктор-методик җыелуны үткәрү | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | 2024 елның 26 сентябреннән, 2025 елның 26 мартыннан |
| 2. | Беренчел хәрби исәпкә куйганда гражданнарны медицина тикшерүен оештыру һәм уздыру | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | 2025 елның 31 мартына кадәр |
| 3. | Гражданнарны хәрби хезмәткә беренчел исәпкә куюдан алып аларны хәрби хезмәткә чакыруга кадәр, аның вакытында төгәлләнүен тикшереп торып, гражданнарны тулы күләмдә медицина тикшерүе уздыру | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) | 2024 елның 30 декабренә кадәр, 2025 елның 30 декабренә кадәр |
| VI. Дәвалау-сәламәтләндерү эше | | | |
| 1. | Беренчел хәрби исәпкә кую нәтиҗәләре буенча, шулай ук хәрби хезмәткә чакыру йомгаклары буенча вакытлыча яраксыз дип табылган 1 - 3 нче номерлы исемлекләргә кертелгән 2005, 2006 елда туган гражданнар белән дәвалау-сәламәтләндерү чараларын үткәрү | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль органнары җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының муниципаль берәмлекләр буенча бүлекләре (килешү буенча) | уку елы дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 2. | Беренчел хәрби исәпкә куелганчы 15 - 16 яшьлек (2008 - 2009 елларда туганнар) гражданнарга профилактик медицина тикшерүләре үткәрү | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль органнары җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча) | 31.08.2024 – 31.05.2025 |
| 3. | Хәрби хезмәткә чакырганга кадәр гражданнар белән дәвалау-савыктыру чараларын уздыруның нәтиҗәлелеген контрольдә тоту | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының территориаль органнары җитәкчеләре, Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләре (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) | 2024 елның 30 декабренә кадәр, 2025 елның 29 июленә кадәр |
| 4. | Укучыларны тикшерүне үткәрүнең барышын һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында көндезге укыту формасында укытуны тәгәлләүчеләрне тикшереп тору | Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы каршындагы тәрбия эше буенча координация советы (килешү буенча) | 2024 елның 30 декабренә кадәр, 2025 елның 14 июленә кадәр |
| VII. Гражданнарны хәрби хезмәткә ирекле рәвештә әзерләү | | | |
| 1. | Россия Федерациясе Оборона министрлыгының хәрби һөнәри белем бирү оешмаларына укырга керү өчен кандидатларны сайлап алуны һәм җибәрүне оештыру | Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) | 01.02.2025 – 28.04.2025 |
| 2. | Суворов хәрби училищеларына, хәрби-музыка училищеларына, кадет корпусларына, Нахимов хәрби-диңгез училищесына укырга керү өчен кандидатларны туплау һәм җибәрү | Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча) | 01.02.2025 – 24.07.2025 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 3. | Спортның авиация, техник һәм хәрби-гамәли төрләре буенча клублар, секцияләр, түгәрәкләр эшен оештыру һәм аларның слетларын үткәрү | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм күрсәтү буенча ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча), ХСӘПТҮҮнең Татарстан Республикасындагы филиалы (килешү буенча) | уку елы дәвамында |
| 4. | Югары белем бирү мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан запастагы офицерларны «Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре» укыту предметын оештыручы мөгаллим вазыйфасына сайлап алуны оештыру | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы (килешү буенча), муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча) | уку елы дәвамында |
| VIII. Гражданнар спортның авиация, техник һәм хәрби-гамәли спорт төрләре белән шөгыльләнү | | | |
| 1. | Спорт клубларын һәм секцияләрне ачуда мәгариф оешмаларына, иҗтимагый берләшмәләренә ярдәм күрсәтү | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм күрсәтү буенча ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү буенча) | уку елы дәвамында |
| 2. | Техник һәм хәрби-гамәли спорт төрләре буенча спорт клублары, секцияләр арасында республикада ярышлар оештыру һәм уздыру | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (килешү | уку елы дәвамында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | буенча), «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм күрсәтү буенча ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе (килешү) | |
| 3. | Муниципаль берәмлекләрдә гражданнарның физик әзерлеген контрольдә тотуны тәэмин итү һәм тест тапшыру буенча муниципаль үзәкләрдә «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормаларын үтәү | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | даими |
| 4. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан патриотик юнәлештәге клублар исәбен алып бару | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | даими |